РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 октябре № 17

Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә җиткән, инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә яки аның бер өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) уналты яшькә җиткән, инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яисә аның бер өлешендә яшәүчеләр - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

5.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

5.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.»;

17.1 пунктының 2 абзацына «яки муниципаль берәмлек халкын» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин